# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баек авыл җирлеге Горбуновка авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

23 ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нчы матдәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче матдәсе нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2023 нче елның 23 нче ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2024 нче елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Горбуновка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең ) сум күләмендә, I-II төркем инвалидлар, Афганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә һәм ЛНР һәм ДНРда махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук тормыш иптәшен (хатынын), балигъ булган балаларны, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итеп, билгеләнгән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1). Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланууда булган автомобиль юлларын карап тоту:

- кышкы чорда Горбуновка авылы Урман урамы юлларын карап тору;
- җәйге Горбуновка авылы Урман урамы юлларын карап тору;
- Горбуновка авылы Урман урамы юлларын төзекләндерү, вак таш һәм гравий белән тигезләү;
- Горбуновка авылы торак пунктының юллары кырындагы үләннәрне чабу;
- кар чистартуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү.

2). Урам яктырту челтәрләрен төзекләндерү:

- Яктырткычлар сатып алу, төзекләндерү, яктырткычларны алыштыру, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү

«РИЗА» - «КАРШЫ»-

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 8 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 5 кеше, бу 62,5% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 5 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 0 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең Горбуновка авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 нче елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Горбуновка авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 000 (бер мең) сум күләмендә,I-II төркем инвалидлар, Афганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан

хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм ЛНР һәм ДНРда махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук тормыш иптәшен (хатынын), балигъ булган балаларны, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1). Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланууда булган автомобиль юлларын карап тоту:

- кышкы чорда Горбуновка авылы Урман урамы юлларын карап тору;
- җәйге чорда Горбуновка авылы Урман урамы юлларын карап тору;
- Горбуновка авылы Урман урамы юлларын төзекләндерү, вак таш һәм гравий белән тигезләү;
- Горбуновка авылы торак пунктының юллары кырындагы үләннәрне чабу;
- кар чистартуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү.

2). Урам яктырту челтәрләрен төзекләндерү:

- Яктырткычлар сатып алу, төзекләндерү, яктырткычларны алыштыру, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Баек авыл җирлеге башлыгы: М.Ф.Фахерлегаянов